СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д. 13, д.Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр урамы, 13 йорты, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366)53-4-32, факс (84366)53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 16 » июль 2021 ел №14

**Урта Курса авыл җирлеге Советының 2015 елның 04 ноябрендәге 12.1 номерлы карары белән расланган Урта Курса авыл җирлеге Советы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021елның 30 апрелендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Урта Курса авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. «Урта Курса авыл җирлеге Советы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Урта Курса авыл җирлеге Советының 2014 елның 04 ноябрендәге 12.1 номерлы карары белән расланган Сеҗе авыл Советының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Урта Курса авыл җирлеге Советының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибен һәм күләмнәрен билгели».

Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре (алга таба - Хезмәткәрләр) дип муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затлары, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары булмаган вазифалар биләүче хезмәткәрләр, шулай ук Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче затлар аңлашыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина